БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК

> 3

«ЯРАТАМ» ДИЕЛДЕМЕ?

> 3

ФОТО-МИЗГЕЛЛӘР

> 4

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

№ 10 | Сишәмбе | 9 ноябрь | 2021 ел

ХӘБИР ИШТИРӘКОВ:

«ӨЛКӘННӘР ҺӘРВАКЫТ САФТА!»

Эшкә нәтиҗә

Республикада яшәүче өлкәннәрнең тормышы күпләрне шаккатырырлык. Алардан картлык үзе дә куркып тора бугай. Әле дә күңел хөрлеген югалтмаган, бар эштә актив, җырлап-биеп яши алар! Киләсе елга Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы оешуга 35 ел тула. Әнә шул уңайдан без оешма җитәкчесе Хәбир ИШТИРӘКОВ белән сөйләштек.

:: Хәбир Газизович, үзегезнең оешма эшчәнлеге хакында сөйләсәгез иде.

– Бүген республикада ветераннарның 55 җирле, 3 меңгә якын беренчел оешмасы бар, шуларда 45 меңнән артык активистыбыз хезмәт итә. Аларның ихтыяҗларын кайгырту өчен бөтен шартлар һәм мөмкинлекләр тудырылган. Оешмаларының барысы да диярлек биналар, кирәкле элемтә чаралары һәм оргтехника белән тәэмин ителгән. Бу эштә безгә дәүләт һәм җирле хакимият органнары ярдәм итә. Алар белән үзара аңлашып эшлибез. 2020 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның карары буенча, оешмадагы өлкәннәрнең читтән торып эшләвен тәэмин итү өчен, 30 данә ноутбук сатып алдык. Алар безнең эшне, бигрәк тә үзизоляция вакытында бик җиңеләйтте. Әмма андый ноутбуклар безгә кимендә тагын 40 данә кирәк әле. Районнарда эшләп килүче оешмалар белән тыгыз элемтәдә торабыз. Бар эшне бергәләп башкарып, фикерләр алышабыз. Ветераннар хәрәкәтендә куратор үзәкләре мөһим урын алып тора. Бездә алар – җидәү. Араларында иң нәтиҗәле эшләүче дип Әлмәт үзәген әйтә алабыз. Алга таба бу эшне тагын да көчәйтергә планлаштырабыз. Район ветераннар советы җитәкчеләренең уртача яше 71не тәшкил итә. Оешманы җитәкләү җиңел эш түгел. Сүз уңаеннан, бу урынга озак вакытлар лаеклы кандидат таба алмаган районнар барын да әйтеп үтәсем килә.

> 2

Хәбәр

Изге күңел иясе

Районыбызның акъәбисе, бар гомерен мәдәният өлкәсенә багышлаган, бик күпләр күңелендә китап укуга мәхәббәт тәрбияләгән Сәүдә апа Әхмәдуллина Апас районы оешуның 90 еллыгы уңаеннан истәлек медаленә, район башлыгының Рәхмәт хатына лаек булды. Шулай ук бу көннәрдә генә Татарстан мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы белән дә бүләкләнде.

– Сезгә район башлыгы исеменнән, гомер буе мәдәният өлкәсендә хезмәт иткәнегез өчен олы рәхмәт сүзләрен җиткерәбез. Бүген дә дөнья мәшәкатьләренә бирешмичә, дин әһеле, остабикә булып хезмәт итәсез. Күп кешегә остаз сез, – диде аңа аппарат җитәкчесе Роза Нурмиева бүләкләрне тапшырганда.

Сәүдә апа Әхмәдуллина тумышы белән Менделеевск якларыннан. Моннан 66 ел элек, кулына диплом алган яшь-яшь кыз бала юллама белән Апас җиренә килә. Хезмәтен Борнаш авылында башлап җибәрә. Эштән курыкмый ул. Өчәр гектар чөгендерен дә эшкәртә, борчак чабарга да йөри, оештыру эшләренең дә үзегендә кайный.

– 33 ел китапханәче булып эшләдем. Гомеремнең иң матур еллары Борнашта узды. Аннан район үзәк китапханәсенә килдем. Кайда гына булсам да, җаным-тәнем белән бирелеп, нәтиҗәләргә ирешеп, макталып хезмәт иттем, – ди Сәүдә апа.

Таләпчән, шул ук вакытта олысына-кечесенә карата игътибарлы, ягымлы, чисталык-пөхтәлек, төгәллек яратучы, матурлыкка гашыйк Сәүдә апа китап укучылар белән уртак телне тиз таба. Китапханә бакчасын чәчәкләргә күмә. Хәтта хәреф таный белмәгән балаларның да китапханәгә тартылуы китапханәче апаның үзен күрү өчен булгандыр, мөгаен. Буяу китапларны биреп, соңрак аларның һәр битен тикшереп кабул итүе белән сакчыл караш уятуын, укырга биргән әсәрләрнең эчтәлеген сорашып белемгә тартуын аңлыйсың. Сәүдә апа үзе дә һәр китапның эчтәлеген белүе белән сокландыра иде.

– Чәчәкләр, гөлләр яратуым әтием Гыйльмулладан күчкән. Борнашта яшәгәндә дә бакчам, ишегалдым, китапханә, клуб бакчасы чәчәкләргә күмелде. Дәлияләрнең миндә 28 төре бар иде. Хәзер дә гөлләр арасында яшим, алар белән сөйләшеп йөрим. Язын бакчага чыгарган чәчәкләрне көзен өйгә алып керәм, – ди ул.

Сәүдә апа һәрчак изге догада яши, йөрәге олы, уйлары саф аның. Район халкына дини тәрбия өләшә, үзе дә белемен һаман арттыра.

– 7 яшьтән намазга баскан кеше мин. Кешеләрне, тормышны яратып, шәригать кануннарын үтәп яшим. Шушы яшемә җитеп, бер генә кеше белән дә ачуланышканым, бер генә кешене дә үпкәләткәнем юк. Бар кешегә дә теләгем изге, – ди Сәүдә апа.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА.
Апас

ХӘБИР ИШТИРӘКОВ:

«ӨЛКӘННӘР ҺӘРВАКЫТ САФТА!»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә.

Бер проблема икенчесен кузгата. Районнарда ветераннар советларына матди ярдәм булырга тиеш. Юк икән, андый шартларда кадрлар проблемасы яшәячәк һәм бу безнең эшкә зыян салачак. Хакимияттәгеләр менә шушы проблемага игътибар итсен иде. Әле шунысын да әйтеп узарга кирәк: ветераннарның җирле советлары җитәкчеләре арасында берничә җәмәгать йөкләмәсен үз җилкәсендә алып баручылар да аз түгел. Алар Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре, инвалидлар оешмасы җитәкчеләре, экспертлар, «Бердәм Россия» партиясенең оператив оешмасын җитәкләгән белгечләр булып та йөриләр. Аларның эшен күрә дә, тиешле бәясен бирә дә белергә кирәк.

:: 2020 ел истәлекле даталарга бай булды. Узган елгы эшләрегезне дә беләсе килә.

– 2020 елда ТАССРның 100 еллыгы һәм Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, бу зур бәйрәмнәргә багышлап, республика ветераннары арасында 2012 нче елдан башлап уздырыла торган VI «Балкыш» республика фестивале оештырылды.

Шулай ук Җиңү бәйрәме алдыннан, республика районнарындагы ветераннар күче белән һәйкәлләр һәм обелисклар буенча ревизия үткәрелде, нәтиҗәләре урыннардагы хакимият органнарына җиткерелде.

Коронавирус пандемиясе белән килеп туган вазгыятьне исәпкә алып, 2020 һәм 2021 елларда күпсанлы чаралар – мини-парадлар, концертлар, ветераннарның йортлары алдында театральләштерелгән тамашалар, өйдә ветераннарны хөрмәтләү оештырылды. Бу эштән безнең ветеран активистларыбыз да читтә калмады.

:: Оешмагыз төрле чаралар аша актив эшләүчеләрне үсендереп тора. Узып баручы елда нинди бәйгеләр булды?

– Без Җиңүнең 75 еллыгына багышланган «Беренчел ветераннар оешмасы» дигән конкурс оештырган идек. 2018–2020 елларда өч этаплы конкурста 400 беренчел ветераннар оешмасы катнашты. 57 оешма призлы урыннар алды, аларга бүләкләр һәм дипломнар бирелде. Конкурс аларның эшчәнлеген активлаштыру өчен яхшы этәргеч булды, аларга көч өстәде. Әлеге бәйгенең май аенда тәмамлануына да карамастан, бу эш җирле ветераннар оешмалары инициативасы белән әлегә кадәр дәвам итә.

:: Гомер озынлыгы турында еш сөйләнелә. Без чит ил әби-бабайларын куып тота алырбызмы?

– Бүген безнең алда гомер озынлыгын арттыру бурычы куела. Кызганыч, әлегә безнең сәламәтлегебезне һәм физик хәлебезне саклау өчен яңа белемнәргә һәм физик камиллеккә омтылыш җитми. Республикада моның өчен шартлар булдырылган. Соңгы 10 елда гына да 3200 социаль-мәдәни объект төзелде, 400дән артык иҗтимагый киңлек төзекләндерелде. Бирегә әгәр матди яктан мөмкинлек тудырылса, ветераннар оешмалары тарафыннан яшьләр белән очрашулар, күргәзмәләр һәм башка чараларны да ешрак уздырып булыр иде.

:: Пандемия безне онлайн тормышка өйрәтте. Өлкәннәр бу агымга иярә алдымы?

– Бер дә югалып калмадылар. Үзизоляциягә киткәч, «Ватсап» төркемендә «Ветераннар иҗаты» яңа онлайн проектын ачып җибәрдек. Аралашулар шунда дәвам итте. Кыска вакыт эчендә төркемдә кул эшләнмәләренең 1000нән артык фотографиясе, сәнгать картиналары, шулай ук автор шигырьләре һәм җырлары урнаштырылды. Шулардан чыгып, «Ветераннар иҗаты» дигән матур альбом чыгарылды, сайтыбызда шул темага багышлап ролик урнаштырылды. Өлкәннәр бәйрәме алдыннан быел Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән «Когда поет душа» дигән фильм күрсәттек. Әлеге эшне тормышка ашыру өчен «Агыйдел» төркеме белән ел буе иҗат иттек. Максатыбыз талантлы өлкәннәрне күрсәтү иде. Әмма кызганыч, әлеге истәлекле һәм тирән мәгънәле фильмның республика телевидениесе каналларында бүгенгә кадәр күрсәтелгәне юк. Юкса аны өлкәннәр генә түгел, яшьләр дә яратып карар иде.

Ветераннар иҗатының чиге юк. Моңа «Балкыш» («Сияние») үзешчән башкаручылар фестивале – ачык мисал. Өлкәннәр, кирәкле шартлар тудырылса, үз талантларын күрсәтә алалар. Без шуңа инандык. Күпме гомер яшәп, колхозда бил бөккән, сыер сауган, трактор йөрткән, мәктәпләрдә балаларга белем биргән кешеләр сәхнәне моңга күмеп җырлый. Аларны сулыш алмыйча тыңлыйсың. Безнең фестиваль күп кенә талантларны ачты. 2012 елда башланган беренче фестивальдә катнашырга 3,5 мең кеше теләк белдерсә, 2020 елда бу чарада 25 меңнән артык кеше катнашты. Узган ел карантин игълан ителгәч, фестивальнең икенче этабы онлайн форматта узды. 46 сәгатьлек видеоматериал җыелды. Әлеге фестивальнең гала-концертын «ВКонтакте» социаль челтәрендә 45 меңнән артык кеше карады.

:: Киләсе елда сезнең оешмага 35 ел тула. Бу чарага әзерләнә башладыгызмы?

– Әзерлек бара. VII «Балкыш» фестивале шул вакыйгага багышланачак дип планлаштырабыз. Һәр җирлектәге ветеран оешмасының эшчәнлеген тагын да яхшырту өчен көч куячакбыз. Ветераннар хәрәкәте үсәргә тиеш.

БӘХЕТ КАРТЛЫКТА КИРӘК

Тигез, бәхетле картлык насыйп булсын, дип телиләр еш кына котлаулар вакытында. Ә нинди була соң «бәхетле картлык»?

Мин бу сорауга җавапны Чишмәбаш авылында гомер итүче Мәүгыйдә апа белән Миневасыйл абый Мәрсетдиновлар гаиләсендә таптым. Бу матур пар – яшьләр өчен тормыш өлгесе.

Миневасыйл абый да, Мәүгыйдә апа да шушы авылда туып-үскәннәр, гаилә корып, тормыш көткәннәр. Миневасыйл абый авылның оста куллы, тәвәккәл егете, Мәүгыйдә апа исә иң чибәр кызларның берсе була.

Хуҗа унсигез ел буе урак вакытында комбайнда эшләгән, «СК-1», «Нива» кыр корабларын иярләгән, шулай ук фермада төзелеш эшләрендә катнашкан.

– Минем дүрт сыйныф белемем бар, сугыш чоры вакытлары иде, укуымны дәвам итеп булмады. Шуңа күрә тормышта барысына да үзлегемнән өйрәнергә туры килде, – диде ул. – Ике ел комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгәннән соң, ул вакыттагы хуҗалык рәисе Камил Шакиров, сиңа комбайн бирергә уйладык дип, мине Янилгә укырга җибәрде. Шуннан соң тырышып хезмәт куйдым, хуҗалык җитәкчесенең йөзенә кызыллык китермәдем, алдыңгы урыннарны яуладым, бик күп бүләкләр алдым. Иң истә калганы – СССР авыл хуҗалыгы министрының Мактау грамотасы һәм 900 сумлык келәм белән бүләкләнү. Бу бик затлы, кыйммәтле бүләк иде, чөнки ул вакытта айлык хезмәт хакы 80–90 сумны тәшкил итте. Аны алырга баргач, кибетчеләр алмашка мотоциклга хәтле тәкъдим итеп карадылар, әмма мин ризалашмадым. Шулай ук сәгатьләр, радиоалгыч һәм башка әйберләр дә бүләк иткәннәре булды.

Миневасыйл абый якын-тирә авылларга балта остасы буларак та билгеле. Ул салган өйләр әле дә хуҗаларына игелекле хезмәт күрсәтә. Аның тагын бер шөгылен язмый калып булмый: озак еллар дәвамында умарта тота икән.

– Бер елны бура бураган чак иде, безнең яндагы һәйкәлне умарта күче сарып алды, шул ук көнне медпункт стенасына тагын бер оя умарта күче килеп кунды. Мин аларның икесен дә җыеп алып кайттым. Шулай итеп, үзлегемнән әлеге шөгыльне дә үзләштерергә туры килде. Аерган саен алар арта бардылар, – диде умартачы.

Картының сөйләгәннәрен әкрен генә җөпләп, авызын каплап, кет-кет көлеп тыңлап утырган Мәүгыйдә апа исә – татар хатын-кызларына хас булганча бик тыйнак, ипле, һәр сүзе күңелне җебетә торган йомшак һәм кайгыртучан. Аның исеме дә бик матур, сирәк очрый торган, мәгънәсе буенча вәгазьче дигәнне аңлата, ди. Әякыннары, аны яратып, Май апа дип дәшәләр икән. Ул биш балалы гаиләдә төпчек кыз булып туып-үскән, бүген бертуганнары арасында берүзе генә исән калган.

Мәүгыйдә апаның әнисе аңа 13 яшь вакытта якты дөньядан китеп барган. Әнисе чирли башлагач, 6 нчы сыйныфтан соң аңа укуын калдырырга туры килгән. Төпчек кыз урын өстенә калган әтисен дә ун ел буе тәрбияләгән. Тавык фермасына эшкә урнашып, шунда хезмәт куйган. Тырыш хезмәте өчен Мактау грамоталары белән бүләкләнгән.

Миневасыйл абый белән Мәүгыйдә апа җиде балага гомер биргәннәр, тик сабыйларының икесе тугач та озак яшәмәгән, ә бер уллары гомер уртасында җитәрәк фаҗигале төстә вафат булган. Калган балаларның исә һәрберсенең үз тормышлары, әмма әти-әни йортына юлны алар бер дә суытмыйлар, өлкәннәрне кадер-хөрмәттән ташламыйлар.

Ризилә КОРБАНОВА.
Кукмара районы

«Авылда безнең яшьтәге кешеләр дә, өлкәнрәкләр дә бар. Әмма картлыкта парлы гомер итүчеләр генә юк, – ди Миневасыйл абый. – Аллаһы Тәгалә безгә шундый бүләк ясаган икән, моны бәхет дими, ни дисең? Бу яшькә кадәр яшәгәч, вакыт җитеп аерылышсак та, бер-беребездән башка озак тормабыз, аерым яшәргә вакыт күп калмады, дип уйлыйм. Яшьләргә шуны әйтәсем килә: гаиләдә бер кешенең генә әйбәт булуыннан мәгънә юк, икеңнең дә бер-береңә карата әйбәт булуы кирәк».

Икең бергә рәхәт

Яңа Кәкерле авылында гомер кичерүче Баһаутдиновлар гаиләсенә дә гомер көзен парлап узу бәхетен биргән.

Глира апа да, Әмирҗан абый да сугыш елларының авырлыгын ачлыгы, ялангачлыгы белән генә түгел, әтисез калулары белән дә кичерәләр, тормыш арбасына да бик яшьли җигеләләр.

Әмирҗан абый Новосибирск якларында өч ел хезмәт итеп, рухын ныгытып, тәҗрибә туплап, туган якларын сагынып кайта. Бәхетен читтән эзләми, киләчәк тормышын туган ягы белән бәйләргә карар кыла. Әмма төп нигез искергән, өйне яңартырга кирәк. Әмирҗан абый акча эшләү максаты белән шахтага юл тота. Өч ел эшләгәннән соң, авылга кайтып, йортны төзекләндерә. Бу вакытка Глира апа белән сүз куешкан, вәгъдәләр бирешкән булалар инде. Тагын бер елдан соң ул аны, кайтып, Казахстан якларына алып китә.

Глира апа – Иске Чүпрәле авылы кызы. 10 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң ук укытучы булып эшли башлый. Казахстанда да әлеге хезмәтен дәвам итә. Төрле милләт балаларын укыта. Глира апа аларны, аеруча татар балаларын, бүген дә күңелендә бер җылылык белән искә ала. Яшь гаиләнең үз балалары да дөньяга аваз сала башлый. Беренче булып Әнәсләре туа. Аның тууы гаиләнең язмышын да башка якка борып җибәрә – алар туган авылларына бөтенләйгә дип кайтып төпләнәләр.

Әмирҗан абый да, Глира апа да бер үк юнәлештә балаларга белем бирү һөнәрен сайлыйлар һәм Яңа Кәкерле мәктәбендә дүрт дистә еллап укыталар. Гаиләдә тагын бер-бер атлы ике ир бала туа, аларда да тик яхшы сыйфатлар гына тәрбияли әти-әни. Улларының өчесе дә тормышта үз урыннарын табып, күркәм гаиләләр корып гомер итәләр.

Гаиләнең бриллиант туена район башлыгы Марат Гафаров, авыл җирлеге башлыгы Радик Мөхәммәтҗанов, ЗАГС бүлеге җитәкчесе Альбина Шәрәфетдинова да килде. Котладылар, бүләкләр тапшырдылар.

«Сөям», «яратам» дигән сүзләр әйтелдеме икән?! Анысы мөһим дә түгелдер инде. Аларның бүген дә бер-берсенә олы хөрмәт белән караулары чит кешегә дә сизелеп тора. «Гаилә бәхетенең сере белән уртаклашыгыз әле», – диюебезгә дә: «Тормыш итү барышында төрле чаклар була. Сабыр була белергә кирәк. Әмма мин Әмирҗанның бервакытта миңа авыр сүз әйткәнен хәтерләмим», – дип мактап куйды картын Глира апа. Башкача була да алмый кебек. Күркәм, итагатьле, гомерлек укытучы Әмирҗан абый олыгайгач та халыкны агарту, белемле итү юлыннан тайпылмый – динебезне өйрәнеп, аның кануннарын үтәп яшәп, шуңа башкаларны да өнди. Авылда Коръән, шатлык мәҗлесләре, мәрхүмнәрне соңгы юлга озату аннан башка узмый.

Гомер буе хезмәттә булган кешеләр бүген дә эшсез тора алмый. Элеккечә күпләп мал асрамасалар да, кош-кортлары бар аларның, зур бакча тоталар. Әмирҗан абый умартачылык белән дә шөгыльләнә.

– Без үзебезне бик бәхетле саныйбыз. Авырлыкны бергә күрдек, тормышны бергә тарттык. Аллага шөкер, авыл халкы, укучыларыбыз бүген дә рәхмәтләр әйтәләр. Бер акыл иясе үзенең яшәве турында: «Бер ишектән кердем, икенчесеннән чыктым», – дигән. Күрәсез, яшәү – бер мизгел, аны матур итеп, кадерен белеп яшәргә кирәк. Хәзер тормышлар да әйбәтләнде, яшәве дә рәхәт, тик гомер генә үтеп бара, – ди Әмирҗан абый.

Гөлия ФӘЙЗОВА.
Чүпрәле районы

Сабада кич утыралар

Кич утыру – милли мәдәниятне саклау һәм үстерү, фольклор халык гореф-гадәтләрен, йолаларын һәм бәйрәмнәрен торгызу максатларында халык традицияләренең берсе. Октябрь аенда Саба районының Шәмәрдән бистәсендә Төзүчеләр урамындагы күпфатирлы йортларда яшәүчеләр өчен «Йөзегемнең исеме – Өммегөлсем» дигән кич утыру узды. Чараны мәдәният йорты массакүләм чаралар үткәрү белгече А.М. Вәлиева алып барды. Чарада катнашучылар күңелле аралашу өчен җыелдылар.

Мондый очрашулар гадәти тормышны төрләндерергә ярдәм итә. Кичә барышында «Биш парлы», «Назалы», «Гөлбану», «Син болай, мин болай…» дип аталган төрле йола уеннары үткәрелде. Концерт номерлары белән Шәмәрдән авыл мәдәният йорты хезмәткәрләре Шәмәрдән мәдәният йорты каршында эшләп килүче үзешчән сәнгатьтә катнашучылар белән берлектә чыгыш ясадылар. Кич утыру өчен якын-тирә йортларда яшәүчеләр бүләкләр әзерләделәр. Кичә барысында да яхшы кәеф уятты һәм уңай эмоцияләр бүләк итте.

СӘЛАМӘТЛЕК – БАЙЛЫК

Сау-сәламәт булып якты дөньяга туган һәркем саулыгын сакларга тиеш икәнен беләбез дә соң… Әмма бу байлыкны мәңгелек дип ялгышабыз.

Карадуган авылының әле бер, әле икенче-өченче урамыннан, «ашыгыч ярдәм» сумкасын күтәреп, шәфкать туташының йөгерә-атлый узуын күреп уфтанабыз: «Тагын кемгә нәрсә булды икән?» Бу хәлне күп тапкыр күрүем мине дә уйландырды… «Шәфкатьле Фәридә, ни булды, хәлең ничек?» – дип соравыма җавап: «Мәдинә апа, аны сөйләгәндә, мин үзем дә тагын бер үлеп терелә бит…»

Һич уйламаганда «вирус»лы ел, аның төрледән-төрле штаммнары…

Ә менә безнең Балтач районы Карадуган авылы халкы бу вирустан оста сакланды. Монда да әлеге дә баягы шәфкать туташы Фәридәгә рәхмәтле без!

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы оештырган күчмә сырхауханә дә авылга килеп җитте. Куандык, чөнки моң-зарыбызны кайсы һәм нинди табибка сөйләргә белми йөргәндә, шәһәр табиблары безне үзләре эзләп килделәр, рәхмәтләребез барысына да ирешсен иде.

Табиблар килүгә әзерлек тә Фәридә Зәкиева өстендә булды.

Без – өлкән яшьтәге, сәламәтлеге какшаган, шулай булса да якты дөньяда яшисе килгән авыл халкы өчен табибларның килүе күктән төшкән могҗиза кебек булды! Алар сабыр гына безне тыңлап, аңлатып, киңәшләрен биреп, дарулар язып озаттылар. Шунда ук кан тапшыру кабинеты да бар иде.

Без, авыл халкы, табибларның авылга килүен оештыручыларга чын күңелдән рәхмәт әйтәбез. Бәхетле булыгыз!

Мәдинә ЗЫЯТДИНОВА.
Балтач районы Карадуган авылы

БЕР ЯШЬЛЕКТӘ, БЕР КАРТЛЫКТА

soovp.kzn.tatar.ru

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 13 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru